ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«МУСЛЮМКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОСЛИМ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРЭМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422960, РТ, Чистопольский район, с.Муслюмкино, ул.Пионерская д.11, тел.(884342) 3-24-45, E-mail: Musl.Ctp@tatar.ru

Постановление  Карар

№8  2019елның 24 декабре

Чистай муниципаль районының
Мөслим авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Бахта авылы гражданнар җыенының 2019 елның «15» ноябрендәге 1 номерлы карары, Мөслим авылы гражданнар җыенының 2019 елның «18» ноябрендәге 2 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Мөслим авыл
җирлеге башлыгы  Ш.Ә. Мәссаров

Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 8 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Мөслим авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан тыш(түләүдән азат ителгән гражданнар категорияләрен күрсәтергә), 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль
районының
Мөслим авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
____________________________________________________________________

Адрес: ____________________________________________________________

______________________________________________________________ нигезендә

Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:______________________________________________

Алучы Банк БИК ___________________________________

Сч. № ______________________________

Алучы Сч. № ____________________________________

ИНН ______________________________________

КПП _______________________________________

КБК _______________ ОКАТО __________________

Түләү билгеләү

____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ____________________________________

М.П. (имза) (тулы имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -

хәбәр (хәбәрнамә) № _____

________________ сум күләмендә

Түләүченең Ф. И. атасының исеме ______________________________________

Адрес: ___________________________________________________________________

Алды «__» _______________ 20__ ел. ___________________________________

(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше _________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.